РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урамы, 21 йорт

тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

29.06.2020 — №21

Олы Кибәче авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.05.2016 елның 22 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында»

Район прокуратурасының 19.06.2020 елның 02-08-02-90-2020 номерлы протесты һәм "Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" 02.12.2009 ел, №390-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Олы Кибәче авыл җирлеге Башкарма комитетының 04.05.2016 елның 22 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктны киләсе эчтәлектәге 3.1.2 пункты белән тулыландырырга:

“Планлы тикшерүнең еллык планына, планлы тикшерүләрне кертү өчен нигез булып,кабул иткән көннән бер ел үткәннән соң кертелә:

- дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган уведомлениегә туры китереп, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау;

- социаль файдаланудагы беренче наемга алынган торак йортның муниципаль реестрында, торак урыннарны наймлаучы булып торучы, эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат булган Социаль файдаланудагы наемга алынган йортларның муниципаль реестрында исәпкә кую (статья исеме 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы редакциясендә);

- юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерүне үткәрү тәмамлануы;

- коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү һәм үзгәртү.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru к

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А.К. Сафин